КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль г.Казань № 184

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында»

2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 610 нчы; 2017 ел, 24 август, 598 нче; 2018 ел, 11 апрель, 447 нче, 2019 ел, 12 апрель, 280 нче; 2021 ел, 28 апрель, 288 нче; 2021 ел, 3 август, 676 нчы, 2021 ел, 01 декабрь, 1152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

коммуналь хезмәтләр, эксплуатация чыгымнары, башка агымдагы чыгымнар, шул исәптән инженерлык челтәрләрен һәм коммуникацияләрне һәм төп чараларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары, клининг, саклау, почта, банк һәм ИТ-хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, китерү, сервис җыемнары, әгъза кертемнәре өчен түләү, канцтоварлар, кәгазьләр, оештыру техникасына комплектлаучы әйберләр сатып алу, картриджлар һәм тоннерлар тутыру, келәмнәрне чистарту чыгымнары;

2.2 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктында «а» пунктчасында:

өченче абзацта «2 263» саннарын «1 562» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «70» саннарын «62» саннарына алмаштырырга;

бишенче абзацта «3 377» саннарын «4 124» саннарына алмаштырырга;

алтынчы абзацта «1 178» саннарын «2 068» саннарына алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) субсидия Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелгәндә:

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда - бирелгән субсидиягә тигез күләмдә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелгән микрозаймнар суммасы;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда - бирелгән субсидиягә тигез күләмдә үз-үзенә эшләүче гражданнарга бирелгән микрозаймнар суммасы;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелгән хезмәтләр саны, кимендә 16 286 берәмлек;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда –экспортка ярдәм күрсәтү үзәге хезмәтләре күрсәтелгәне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, кимендә 50 берәмлек;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда - хезмәт күрсәтүләр алган бизнес алып барырга теләүче уникаль гражданнар, эш башлаучы һәм эшләүче эшкуарлар саны, кимендә 11 100 ккеше;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – ярдәм күрсәтелүче, шул исәптән уку

программаларын үткән үзмәшгуль гражданнар саны, кимендә 10 кеше;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының алтынчы абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – чараларны тормышка ашыруга җәлеп ителгән затлар саны, кимендә 1 040 кеше һәм (яки) онлайн һәм офлайн массакүләм мәгълүмат чараларына, социаль медиага чыгу (аларда публикацияләр) саны – кимендә 1 518 берәмлек.

Әлеге пунктчада күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – субсидия бирү елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

2.12 пунктта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырарга;

2.14 пунктның дүртенче абзацында «календарь көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә» сүзләрен «эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә" сүзләренә алмаштырырга;

2. Бу карар (гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның егерме беренче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин